| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«14» февраль 2020 ел Олы Кайбыч ав. № 218

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә сайланулы органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү нормативлары күләме, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2018 елның 23 апрелендәге 121 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәткә түләү күләме, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2018 елның 23 апрелендәге 121 номерлы (2018 елның 14 декабрендәге 144 номерлы үзгәрешләре белән) расланган карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгына, Башлык урынбасарына, Башкарма комитет җитәкчесенә, Контроль-хисап палатасы рәисенә ай саен өстәмә акчалата түләү күләмнәре 18 нче кушымта нигезендә.»;
нче кушымтаның 12 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгына еллык түләүле отпускны биргәндә айлык акчалата түләүдән һәм бер мәртәбә түләүдән тыш, 18

нче кушымта нигезендә айлык акчалата бүләкләүләр, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен 13 нче кушымта нигезендә айлык өстәмә түләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр башкарыла. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгына айлык акчалата түләүләрнең җыелма күләме «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләү турында» 2006 елның 27 мартындагы ПУ-122 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә Татарстан Республикасы министрына айлык акчалата түләүләрнең 0,9 күләменнән арта алмый.»;

- 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының
2018 елның 23 апрелендәге
121 номерлы карарына
5 нче кушымта

**АЕРУЧА МӨҺИМ ҺӘМ КАТЛАУЛЫ ЭШЛӘР БАШКАРГАН ӨЧЕН ПРЕМИЯЛӘР ТҮЛӘҮНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ КҮЛӘМЕ ҺӘМ ТӘРТИБЕ**

1. Муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү, җирле үзидарә органнарына йөкләнгән вәкаләтләрне җаваплылык дәрәҗәсендә үтәү, башкарыла торган бурычларның сыйфатын яхшырту, вазыйфаи инструкциядә каралган вазыйфаи бурычларны вакытында һәм намус белән үтәгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә алар тарафыннан аеруча мөһим һәм катлаулы эшләр башкарган өчен премия түләнә.

2. Хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә аеруча мөһим һәм катлаулы эшләрне башкарган өчен муниципаль хезмәткәрләргә премияләр (алга таба - премияләр) түләү җирле үзидарәнең һәм муниципаль органның тиешле органы бурычларын һәм функцияләрен тәэмин итүне исәпкә алып ай саен һәм эш нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органы (җирле орган) җитәкчесенең әлеге Тәртип нигезендә кабул ителгән карары буенча ел дәвамында башкарыла.

3. Премияләр муниципаль хезмәткәрләргә яллаучының (эш бирүченең) вәкиле тарафыннан җирле үзидарә органы яисә муниципаль орган хезмәте өчен түләү фондында каралган акчалар чикләрендә шул максатларга түләнә һәм түбәндәгеләргә бәйле рәвештә билгеләнә:

тиешле җирле үзидарә органына һәм муниципаль органга йөкләнгән бурычларны, вазыйфаларны үтәүне тәэмин итү һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча хезмәткәрнең шәхси кертеме;

- хезмәткәрләрнең биремнәрне үтәүнең катлаулылыгы, мөһимлеге һәм сыйфаты, ирешелгән нәтиҗәләрнең нәтиҗәлелеге;
- хезмәткәрнең вазыйфаи инструкцияне башкару нәтиҗәләре;
- хезмәт дисциплинасын үтәү.

Премияләр күләме абсолют күләмдә (сумнарда), шулай ук акчалата түләүгә яки

муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасы буенча вазыйфаи окладка тапкырлап билгеләнә ала.

5. Премияне түләүгә җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесенең хокукый акты нигез була.

түбәндәге эчтәлекле 18 нче кушымта өстәргә:

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының
2018 елның 23 апрелендәге
121 номерлы карарына
18 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгына, Башлык урынбасарына, Контроль-хисап палатасы рәисенә, Башкарма комитет җитәкчесенә ай саен өстәмә акчалата түләү күләмнәре**

| Вазыйфа атамасы | Айлык акчалата түләү күләме |
|---|---|
| Башлык | 70577 |
| Башлык урынбасары | 30110 |
| Башкарма комитет җитәкчесе | 19345 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 14895 |

---

Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Кайбыч муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Совет Рәисе А.И.Рәхмәтуллин